Җиләккә кытлык булмаячак

Татарстанда җиләккә кытлык тиздән булмаячак кебек. Республикабызда җиләк-җимеш үстерү һәм сату буенча махсус кооператив төзергә уйлыйлар. Бер үк вакытта кара бөрлегән, карлыган, кура җиләге дә сатылачак.

4 БИТ

2017 ел – Галимҗан Баруди елы

Татарстан Диния нәзарәте тарафыннан 2017 ел – Галимҗан Баруди елы дип игълан ителде. Әлеге тәкъдим белән Диния нәзарәтендә узган пленумда мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин чыкты, һәм ул бертавыштан хупланды, дип хәбәр итә dumrt.ru.

5 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Сишәмбе | 17.01.2017 | №3 (5765)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

ПАРИЖНЫ САБАНТУЙ БЕЛӘН ЯУЛАЯЧАКБЫЗ

Казанда узган ел 2 миллион 500 мең турист булып киткән. Шәһәрнең әкияттәгедәй матур манзарасын күзәтер өчен, Казансу елгасы ярындагы «Казан» гаилә үзәге түбәсенә 110 мең кеше менгән.

Дамир БӘДРИЕВ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

– Туристлар саны аннан алдагы елдагыдан 16 процентка күбрәк. «Казан» халыкара аэропортыннан гына да ике миллионга якын пассажир файдаланды. Казан Кремлендәге экскурсияләрдә 2,8 миллион кеше катнашты, – дип хәбәр итте башкаланың туристлыкны үстерүгә теләктәшлек комитеты директоры Дарья Санникова кичә «эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә.

Элегрәк туристлар Казанга бер-ике көнгә генә килгән булса, хәзер уртача күрсәткеч – дүрт көн. Хәтта кышкы айларда да Казанны сайлаучылар саны арта бара. Иске Татар бистәсендәге Яңа ел ярминкәсенә 66 мең турист килгән. Дарья Санникова сөйләгәнчә, Казанда туристлар һәм кунаклар өчен төрле мәдәни чаралар бик күп. Болар арасында: мэр кубогына «Казан җилкәннәре» («Паруса Казани») музейлар регатасы, Сабан туена бүләк җыю һәм, әлбәттә, Сабантуй үзе, «Берләшкән шәһәрләр һәм Җирле хакимият» башкарма бюросы утырышы, Казан велотөне, «Тәмле Казан» гастрономия фестивале, «Хоровая Казань» хәйрия фестивале, Алла Духованың TODES балет мәктәп-студиясе, шулай ук Казан Ратушасындагы джаз фестивальләре.

– Ил эчендәге туристлыкны үстерү максатларында Уфа, Волгоград, Ульяновск, Екатеринбург, Түбән Новгород, Новосибирск шәһәрләре белән килешүләр төзелде. Халыкара аренада Париж белән килешү кабул иттек. Алар туристлык өлкәсендә тәҗрибә уртаклашырга бик теләп ризалаштылар. Казанда «Париж модасы», урам театры, «Француз аш-сулары» көннәре узачак. Без дә анда мәдәни чаралар оештырачакбыз. Казанны таныту максатларында, татар халкының милли бәйрәме Сабан туен Парижда да уткәрү нияте бар. Казахстан, Әзәрбайҗан һәм ерак илләрдән, Кытай, Германия, Англия туристлык базарларына үтеп керү юнәлешендә чаралар күрелә.

Олимпия уеннары узганчыга кадәр Барселонаны да күпләр әллә ни игътибарга алмаган. Хәзер анда елына миллионлаган турист була. Казанны дөньяга танытуда 2013 елгы Универсиада шулай ук зур роль уйнады. Бәхетебезгә, тагын олы спорт вакыйгалары көтелә. Казанда быелның җәендә – Конфедерация кубогы, ә 2018 елда Футбол буенча дөнья чемпионатының төркем матчлары узачак. Бу – туристлар агымын 10-15 процентка арттырып җибәрер дип фаразлана.

Кытайлыларга Татарстан «Американы ачу» кебек яңалык булган. Әлеге илдән туристлар саны кискен үсештә. Кытайлыларны Казанның борынгы шәһәр булуы, Ленин музейлары, үзенчәлекле архитектурасы җәлеп итә.

– Кытайның Гуань-Жу шәһәрендә Казанны, туристлык үзәге сыйфатында, электрон мәгълүмат чараларында рекламалыйлар хәтта, – диде Дарья Санникова.

Казан, мәдәни-күңел ачу мөмкинлекләреннән тыш, тарих, мәгариф, фән, медицина, эшкуарлык юнәлешләрендә дә көчле.

– 11 ел элек Казанга елына 500 мең турист килә иде. Туристлык үсеше куанычлы, узган ел – 2,5 миллион турист, бу – әйбәт сан. Ләкин безгә көндәшлеккә сәләтлелекне дә даими нығытырга, иминлекне сакларга, кунакчыллык сыйфатларыбызны югалтмаска кирәк, – дип сөйләшүгә йомгак ясады шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе Денис Калинкин.

«Бердәм Россия» Президент сайлауларына бүгеннән әзерләнә башлый

«Бердәм Россия» Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстан төбәк бүлеге соңгы дүрт елдагы эшчәнлегенә нәтиҗә ясады. Казанның «Корстон» сәүдә һәм күңел ачу үзәгендә аларның XXVI конференциясе узды.

tatarstan.ru

Алисә САБИРОВА

Конференциядә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, «Яшь гвардия» вәкилләре, Татарстан Республикасы исеменнән булган Россия Дәүләт Думасы депутатлары һәм 298 делегат катнашты. Әйтергә кирәк, Россия Дәүләт Думасында республика делегатлары иң күп өлешен тәшкил итә.

«Бердәм Россия» партиясенең Генераль советы сәркатибе, Россия Дәүләт Думасы рәисе урынбасары Сергей Неверов партия эшенең төп күрсәткече булып сайлаулар тора дип белдерде.

– Былтыр 18 сентябрьдә Дәүләт Думасына депутатлар сайлау нәтиҗәсе халыкның безнең партия юнәлешен хуплавын күрсәтте. Партиянең төбәк бүлеге уңышлы сайлау программасы алып барды («Бердәм Россия» өчен ике миллионнан артык татарстанлы тавыш биргән иде). Республикада 21 федераль партия проектыннан тыш, тугыз төбәк проекты гамәлдә. Хәзерге вакытта партиянең төп бурычы – сайлау алды вакытында тәкъдим ителгән программаны тормышка ашыру. Программалар халык белән аралашудан кабул иткән тәкъдимнәрне дә истә тотып төзеләчәк, – диде Сергей Неверов.

«Бердәм Россия» Бөтенроссия сәяси партиясе Татарстан төбәк бүлеге сәркатибе, Татарстан Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин белдергәнчә, «Бердәмроссия»леләр Татарстан башкарма хакимиятенең нигезен тәшкил итә.

– Соңгы елларда без партиянең позицияләрен ныгыту, партия сафларын арттыру юнәлешендә саллы эш башкардык. Татарстанда «Бердәм Россия» партиясенә керүчеләр саны 4 меңгә артты. Бүген 45 җирле һәм 1637 беренчел бүлекләрдә 137 мең татарстанлы исәпләнә, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Татарстан «Бердәм Россия» позицияләрен ныгыту өчен үз өлешен кертәчәк, дип белдерде Президент Рөстәм Миңнеханов.

– Партиянең 15 еллык эшчәнлегенә нәтиҗә ясап, Россия Президенты Владимир Путин «Бердәм Россия» илнең сәяси тормышында мөһим роль уйный дип белдергән иде. Монда Фәрит Мөхәммәтшин җитәкчелегендәге төбәк бүлегенең дә өлеше зур. Соңгы сайлаулар вакытында да эшебезнең югары нәтиҗәсен күрсәттек. Татарстан үсештә. Узган ел нәтиҗәләре буенча, сәнәгать җитештерү индексы 2015 ел дәрәҗәсенең 103,5-103,6 процентын тәшкил итә, тулаем төбәк продукты 2 триллион сумга якынлашты. Икътисади үсеш нигезендә республиканың социаль үсешен дә тәэмин итәргә кирәк. Сәламәтлек саклау, спорт, мәгариф һәм фән системаларын камилләштерү, мәдәният дәрәҗәсен күтәрү, халыкның яшәү дәрәҗәсен яхшырту буенча җитди эш алып бару мөһим, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстан лидеры җитәкчеләр алдында торган проблемаларга да тукталып китте. Араларында алданган өлешчеләрне торак белән тәэмин итү мәсьәләсе, «Татфондбанк» белән бәйле хәлләр дә бар.

– Партиянең уңышы турыдантуры заман белән бергә атлаудан тора. Идарәче партия исеме «Бердәм Россия»не халык алдында аеруча җаваплы булырга этәрә. Халыкка якынрак булырга, аның белән аралашырга, иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек итәргә кирәк. Бу хезмәттәшлек традицияләргә ихтирам, гражданлык җәмгыяте институтына өлеш кертүгә нигезләнгән булырга тиеш, – диде Президент.

Рөстәм Миңнеханов шулай ук 2018 елда булачак Россия Федерациясе Президенты сайлауларына инде бүгеннән әзерләнә башларга кирәк дип белдерде.

– 2017 елның эш нәтиҗәләре бу сайлауларга бер адым булачак, – диде ул.

«Бердәм Россия»нең Татарстан төбәк бүлеге сәркатибе – кабат Фәрит Мөхәммәтшин. Аны яшерен тавыш бирү юлы белән биш елга сайладылар.

– Нәтиҗә көтелмәгән, ләкин ышандырырлык булды. Партия Фәрит Хәйруллович бүген биш еллык җитәкчелекне ышанып тапшырган икән, бу – югары күрсәткеч. Илдә ул – абруйлы кеше. Мин үзем дә аннан күп нәрсәгә өйрәнәм. Ярдәмегез өчен зур рәхмәт сезгә. Шундый җаваплы эшкә сайлануыгыз белән котлыйм, – диде Сергей Неверов.

Үз чиратында Фәрит Мөхәммәтшин әлеге җаваплы вазифаны аңа ышанып тапшырганга рәхмәт әйтте һәм ышанычны акларга сүз бирде.

– «Бердәм Россия»гә тере структура булырга, конструктив диалогларга һәм хезмәттәшлеккә әзер булырга кирәк. Партиянең төбәк бүлеге ышанычны аклау өчен көченнән килгәнне эшләячәк. Илнең тотрыклы үсеше, гражданлык мәнфәгатьләрен яклау, халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, Россия Президенты Владимир Путинның курсына тәләктәшлек күрсәтү, болар – «Бердәм Россия» партиясенең Татарстан бүлегенең принципиаль позициясе. Сайлаулар булмаган елны партия эшчәнлеген сыйфатлырак, тагын да нәтиҗәлерәк итәргә кирәк, – дип белдерде ул.

«Татфондбанк»ны кем коткарачак?

«Татфондбанк»ны коткарып калу юлында «Кипр сценарие»н кулланырга уйлыйлар. Гади тел белән әйткәндә, эре кертемчеләрнең акчаларын капиталга кушарга телиләр. Банкны санацияләү бу юл белән башкарылса, «Татфондбанк» дәүләт акчаларына түгел, ә кредиторлар хисабына коткарылган беренче кредит оешмасы булачак.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Татарстанның икътисад министры Артем Здунов әйтүенчә, республика хакимияте дә «Татфондбанк»ка кагылышлы сөйләшүләрдә кредит оешмасын саклап калу ягында. «Кипр сценарие»н икътисадчылар, икенче төрле, bail-in термины белән дә атыйлар. Мәскәүдә Гайдар форумында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та «Татфондбанк»ны коткару өчен әлеге ысулны куллану ихтималы турында әйткән иде. Бу хакта газетабызның узган саннарында хәбәр иттек.

– Әгәр санатор ачыкланса, без тәрле яклап ярдәм итәргә әзер. Эре компанияләр депозитларын акцияләргә капиталлаштырсын өчен, шушы компанияләр белән сөйләшүләр алып барабыз. Хәзер барысы да Үзәк Банк нинди карар кабул итүеннән тора, – дип аңлаткан иде Рөстәм Миңнеханов. «Татнефть» акционерлык җәмгыяте «Татфондбанк»та 5 миллиард сум тирәсе акча саклый, ләкин алар хәзер кулланышсыз тора. Кыскасы, «Татфондбанк» санацияләнсә, «Татнефть» тә депозитларын банк акцияләренә алыштырырга әзер.

Үзәк Банк исәпләвенчә, банкны коткаручы кредиторлар ролендә счетларында 2016 елның декабренә 100 миллион сумнан артык акча саклаган клиентлар була ала, дип яза «Известия».

Сүз уңаеннан, Үзәк банк, кредиторлар алдындагы бурычларын вакытында үтәмәгән өчен, «Булгар банк»ның да лицензиясен алган. Хәзер банкка вакытлыча администрация кертелгән. Зыян күрүчеләр акчаларын 30 гыйнвардан да соңга калмыйча кайтара алачак. «Булгар банк»та иминиятләштерелгән кертемнәре булганнарга акчаларны кайтарырга әзер банк-агентлар 20 гыйнварга кадәр билгеле булачак.

tatarstan.ru

«Салават күпере»ндә өй туе

«Салават күпере» торак комплексындагы йортларның төзелеп бетүен минутлап көтүчеләр дә бар. Социаль ипотека программасы буенча торак отып та, әле күчүенә алмаучылар, вакытлыча фатирларда яшәүчеләр өчен һәр мизгел санаулы.

«Салават күпере» торак комплексындагы йортларга күчүнең барышында проблемалар җитәрлек иде. Ачкыч алганнан соң да торакларның сыйфатыннан канәгатьсезлек белдерүчеләр булды. Киров районына кергән бу урыннан торак алган кешеләр берничә мәртәбә пикетка да чыкты, төзелеш эшләрен тизләтүне сорап, республика җитәкчелегенә дә мөрәҗәгать итте. Күптән түгел Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «Салават күпере» торак комплексында үзе дә булган иде. Ул анда объектларның әзерлек этаплары белән танышты һәм эшче кулларның җитәрлек булмавын искәртте. «Салават күпере» торак комплексында кайбер йортларны тапшыру сроклары сузылуына басым ясап, бу уңайдан фатир көтүчеләрнең канәгатьсезлеге урынлы икәнен әйтеп, төзелеш эшләрен тизләтергә кушкан иде.

Ниһаять, «Салават күпере» торак комплексында төзелеш номеры 13-4нче йортка халыкны күчерә башладылар. Татарстан Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы матбугат хезмәте хәбәр итүенчә, бу йорттагы эшләрне «Ак таш» төзелеш компаниясе башкарган. Йортта 102 фатир исәпләнә.

Мидхәт ШӘРИФУЛЛИН, Дәүләт торак фонды директоры киңәшчесе:

– Социаль ипотека программасы буенча фатир алган кешеләр, йортлар озак төзелә, дип зарлана. Төзелеш таләпләре буенча, күпкатлы йортлар 1,5 ел дәвамында салына. Төзелешне гел күзәтеп торырга, җитешсезлекләр юкмы, нигезе ныкмы икәнен тикшереп торырга кирәк. Шуңа да озак еллар төзелгән йортлар озын гомерле, ышанычлы була, күрәсең.

2005 елдан 2016 елга кадәр Татарстанда 118 мең гаилә социаль ипотека программасы буенча фатирлы булды. Аларның яртысы диярлек ипотека буенча кредитларын инде түләп бетерде.

«Илбашы» китабы дөнья күрде

Язучы Рабит Батулла Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев турында китап язган. Ул аны «Илбашы» дип атаган.

– Әлеге китап – әдәби-документаль әсәрләр җыелмасы. Бирегә 76 хикәя язылды. Төп-төгәл документлар да, аннан соң язучы фантазиясенең Минтимер Шәриповичның мантыйгына буйсына торган өлешләре дә бар. Без бит бер чор кешеләре. Балачагыбыз, яшьлек елларыбыз бер вакытка туры килә. Икебез дә әти-әниләр белән бергә абзарда, мал-туар тирәсендә кайнашып чыныкканбыз, үскәнбез, карашлар да охшаш. Икебез дә ат яратабыз. Кыскасы, хәтта язучы фантазиясе кергән өлешләрдә дә ялган юк. 76 хикәянең нигезенә Минтимер Шәймиев үз-үзен белә башлаган вакыттан, ягъни дүрт яшьләр тирәсендәге вакыйгалардан башлап, бүгенге көнгә кадәрге хәлләр салынган. Аның нинди сәяси һәм милли киртәләр аша узуы, аларны үзенең акылы, зиһене һәм кешелеклелеге нәтиҗәсендә ничек җиңел чыгуы турында тасвирлана, – диде «Шәһри Казан» газетасы хәбәрчесенә Рабит әфәнде.

«Илбашы» китабын Минтимер Шәймиев үзе берничә тапкыр укып чыккан инде.

– Китапны эшләгән вакытта Минтимер Шәрипович үз төзәтмәләрен дә кертте. Вакыйгалар, даталарда бераз хаталар бар иде. Моннан тыш, хезмәтнең мөхәррире Газинур Моратның зур ярдәме тиде. Төгәл документлар белән эшләгәндә, Татарстан Дәүләт Киңәшчесе ярдәмчесе Нурсөя Шәйдуллина да бик нык булышты, – ди китап авторы.

Язучы сүзләренә караганда, йомшак тышлы 14 табаклы, иллюстрацияләр белән баетылган китап шушы көннәрдә сатуга чыгачак.

– Бу инде хәзер минем китап түгел, ә халыкныкы. Үзем дә тагын бер тапкыр яңабаштан укып чыгармын дип торам. Эшемнән канәгать калдым. Ә инде халык ни әйтер – анысын соңрак белербез, – диде Рабит Батулла.

Зөһрә САДЫЙКОВА.

Бәхил бул, Ралина...

Кичә Казанда Александров исемендәге Россия армиясе җыр һәм бию ансамбленең балет артисты – Ту-154 һәлакәтендә гомере өзелгән Ралина Гыйльманова белән хушлаштылар. Ул Юдино бистәсендәге зиратта мөселманча җирләнде.

Матәм чарасы Казанның Киров районында, артист яшәгән йорт ишегалдында узды. Ралинаның җәсәде Россия Саклану министрлыгы күзәтчелеге астында Казанга махсус борт белән кайтартылган.

– Бүген безнең барыбыз өчен дә авыр көн, без Ралина белән хушлашабыз. Яшь, матур, алда дөнья кадәр перспективалары булган кызны, кызганычка, шушы фаҗигале очрак бездән алып китте. Якты истәлеге калсын, – диде Татарстан мәдәният министры Айрат Сибагатуллин, аны соңгы юлга озатканда.

Җыр һәм бию ансамбленең сәнгать җитәкчесе Айрат Хәмитов Ралина Гыйльманованың үз укучысы булуын һәм аның белән һәрчак горурлануы хакында сөйләде:

– Балаларның балаларына да мондый хәсрәтләр күрергә язмасын. Ралинаның әти-әнисенә, туганнарына Ходай сабырлык бирсен, – диде ул.

Ралина укыган 15нче татар гимназиясенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы Мәулия Габдуллина исә уку йортында артистның истәлек почмагы булдырылачагы хакында хәбәр итте, дип яза «Татар-информ» агентлыгы.

Ралина Казанда туган. Хореография училищесында һәм шул ук вакытта Мәскәү дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетында укыган. Шуннан соң «Кострома» балетына эшкә алына, ә 2014 елда аны А.В.Александров исемендәге Россия армиясе җыр һәм бию ансамбленә кабул итәләр.

Исегезгә төшерәбез, Ралина Гыйльманованың гомере 25 декабрь көнне Сочи шәһәре янында булган Ту-154 авиаһәлакәте аркасында өзелде. Ул вакытта самолеттагы 85 пассажир һәм сигез экипаж әгъзасы һәлак булды.

Кичә иртәнге якта тагын бер очкычның һәлакәткә очравы турында мәгълүм булды. Кыргызстан башкаласы Бишкәктә Boeing 747 йөк очкычы «Манас» аэропортына төшкәндә фаҗигагә тарый.

Очкыч аэропорт янында дачалар урнашкан бистә өстенә килеп төшкән. Һәлакәт урынында унбишләп йорт җимерелгән, ике йорт янган. Әлеге авиаһәлакәттә кимендә 32 кешенең, шул исәптән

kpcdn.net

алты баланың һәм экипаждан дүрт кешенең, пилотның гомере өзелгән, тагын сигез кеше авыр хәлдә хастаханәгә озатылган, дачалар бистәсендә 32 торак йорт җимерелгән.

Кыргызстанның транспорт һәм юллар министры Жамшитбек Калилов хәбәр иткәнчә, «Боинг 747» йөк очкычын һәлакәткә китергән башлангыч сәбәп – «Манас» аэропортына утырганда очкычлар төшү юлына туры килә алмавы.

Җиләккә кытлык булмаячак

Билгеле булганча, Татарстанда үстерелгән яшелчә, җиләк-җимеш республика халкын тулысынча тәэмин итәргә җитми. Кибетләрдә махсус контейнерларда читтән кайтарыла торган җиләкләрнең, гадәттә, тәме юк. Күбесе ашламалар ярдәмендә тиз өлгертелгәннәр. Шуңа да Татарстанда җитештерелгән экологик яктан чиста җиләккә ихтыяҗ зур.

Татарстан халкын мөмкин кадәр күбрәк күләмдә җиләк белән тәэмин итү максатында, республикада «Татарстан бакчалары» программасы эшләп килә. Аның нигезендә, республика районнарында җиләк кластерлары ачу күздә тотыла. Яшел Үзән районының Олы Яке авылындагы «Ягодная долина» теплица хуҗалыгы урнәгендә, Әлмәттә дә җиләк үстерә башладылар. Былтыр Ямаш авылында «Ягодная долина» плантациясендә беренче уңышны җыеп алдылар.

«ШК»га бер әңгәмәсендә Яшел Үзән районындагы «Ягодная долина» крестьян-фермерлык хуҗалыгы җитәкчесе Илдар Ситдыйков:

– Безгә эшмәкәрләр еш мөрәҗәгать итә, күпләп җиләк сатып алырга телиләр, әмма безнең җиләк кырдан ерак китә алмый, хәтта сатуга чыгарырга да өлгермибез. Елына 15-25 тонналап уңыш алсак та, бу Казан халкының бер процентын гына тәэмин итәргә җитәдер. Шуңа да эшне башкаларга да өйрәтәсе килә, – дигән иде.

Татарстанда җиләккә кытлык тиздән булмаячак кебек. Республикабызда җиләк-җимеш үстерү һәм сату буенча махсус кооператив төзергә уйлыйлар. Бер үк вакытта кара бөрлегән, карлыган, кура җиләге дә сатылачак. Әлеге эштә «Ягодная долина» крестьян-фермерлык хуҗалыгының өлеше зур. Аларда Голландия, Италия, Германия кебек чит илләрдән тәҗрибә туплап кайткан белгечләр эшли. Хуҗалык җитештергән җиләкнең сыйфатыннан халык канәгать. Әлегә бу эш белән шөгыльләнергә теләгән кешеләр арасында сайлап алу бара. Бу эшкә алынучыларга Яшел Үзән, Әлмәт җирлекләреннән озак вакытка арендага кишәрлекләр бүленеп биреләчәк. «Ягодная долина» хуҗалыгы үсентеләр, технология белән дә тәэмин итәргә әзер.

Сүз уңаеннан, хәзерге вакытта хәтта һөнәрен алыштырып, җиләк үстерү белән шөгыльләнергә теләүчеләр дә бар икән.

«Worldskills»та катнашучылар инглизчә өйрәнә

Кичә Боровое Матюшино бистәсендәге «Идел» Яшьләр үзәгендә «Worldskills» эшче һөнәрләр чемпионатына әзерләнүче Татарстан җыелма командасының беренче киңәйтелгән слеты башланды. Ике көн дәвамында яшь белгечләр җаваплы ярыш алдыннан дулкынланмаска һәм инглизчә сөйләшергә өйрәнә.

– Мондый зур ярышларда катнашу өчен яшьләргә һөнәри белемнәр генә җитми. Иң беренче чиратта команда белән эшли белергә, бер-береңне аңларга, ресурслар белән идарә итәргә кирәк. Шулай ук стрессларга чыдам булу да зарур, – диде сменаны оештыручы Тимур Бәхтияров.

Сменаның төп максаты һөнәри белемнәрне арттыру түгел. Алар болай да инде көн саен бу юнәлештә эшли. Ярышлар алдыннан көч туплау, илһам алу, позитив фикер йөртү кебек әйберләр дә җиңү өчен кирәкле шарт. Яшьләр белән профессиональ психологлар шөгыльләнәчәк. Һәр кешегә шәхес картасы төзелә, аның нигезендә, укучылар киләчәктә «Кайсы өлкәдә үзеңне үстерергә була?» дигән сорауга җавап таба алачак.

«Worldskills» чемпионатында инде үзен сынап карарга өлгергән яшьләр: «Ярышларда иң төп авырлык – тел белмәү», – дип белдергән. Шуңа да 17 гыйнвар көнне «БизнесИнсайт» үсеш һәм персоналга белем бирү үзәгендә Education First оешмасы укытучылары яшьләргә инглиз теле дәресләре бирәчәк. Алдан тапшырган тест нигезендә, укучыларның белем дәрәҗәсе сынала.

Исегезгә төшерәбез, 2019 елда Казан «Worldskills» халыкара чемпионатын кабул итәчәк. Махсус төзелгән полигон-лабораторияләрдә яшь галимнәр, уйлап табучылар, пешекче, тегүче, монтажчы һ.б. дистәләгән эшче «Үз эшенең остасы» дигән абруйлы исем өчен көрәшәчәк.

Татарстан халкы республикакүләм иҗтимагый экология кабул итү хезмәтенә табигатьне саклау законнары бозылу турында Telegram һәм WhatsApp мессенджерлары аша хәбәр итә алалар. Яңа элемтә каналы экология һәм иҗтимагый киңлекләр елында барлыкка килде. Хәбәрләр тәүлек әйләнәсе +79872169779 номеры буенча кабул ителә.

Чүплек күрсәң, хәбәр ит

Telegram һәм WhatsApp аша татарстанлылар Экология министрлыгы инспекторларына законсыз барлыкка килгән чүп өемнәре, гомуми таралыш алган файдалы казылмаларны лицензиясез алу, су объектына баруны чикләү, сулыкларга, туфракка зарарлы матдәләр ыргыту, һаваны пычрату турында хәбәр итә ала.

Исегезгә төшерәбез, шулай ук **(843) 267-68-67** «кайнар элемтә» телефоны, eco.signal@tatar.ru электрон почтасы, интернет аша кабул итү хезмәте (**http://eco.tatarstan.ru/rus/priem.htm**), «Халык контроле» дәүләт мәгълүмати системасы һәм «Мәктәп экопатруле» мобиль кушымтасы эшләп килә. Моннан кала, фото яисә видеофиксация белән, табигатьне саклау законнарын бозу очракларын оператив рәвештә тиешле органнарга җибәргән гражданнарга акчалата түләү каралган. 2016 елда республика халкыннан табигатьне саклау законнарын бозу очраклары буенча 10 меңнән артык хәбәр килгән, дип хәбәр итә Татарстанның Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы матбугат хезмәте.

Сабыйлар бәхете хакына

Ярдәмгә мохтаҗ сабыйлары һәм картлары бәхетле булганда гына ил тулы бәхетле була. Соңгы вакытта ялгыз картларны гаиләләргә урнаштырып, аларның тормыш көзен ямьләндерү турында да сүз бара. Ә инде төрле сәбәпләр белән ятим калган (боларга ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгәннәрнең балалары – социаль ятимнәр дә керә) балаларны гаиләләргә урнаштыру эше республикабызда 2000 еллар башында ук башланган иде инде. 2007 елларда бу изге гамәл тагын да киңрәк колач алды.

Светлана Богова, Татьяна Степанова һәм ирле-хатынлы Рәисә Миңнуллина, Наил Латыйпов.
Автор фотосы

Ныклы гаиләләрнең җылы ояларында күп кенә ятимнәрнең язмыш гаделсезлеге аркасында каткан күңелләре эреде. Республикабызда мондый гаиләләрне берләштерә, кирәк чакта ярдәм кулы сузарга әзер торган «Без бергә!» иҗтимагый оешмасы да бар. Ул мондый гаиләләрнең санын һәм сыйфатын арттыру, аларны пропагандалау буенча күп кенә игелекле эшләр башкара. «Ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны гаиләләргә урнаштыруда алмаш гаиләләр әзерләүдә ярдәм итүче үзәк»тә (Горкий шоссесы урамы, 41 а йортта урнашкан) күптән түгел генә тагын бер мөһим вакыйга булды. Үзәк белгечләре: психологлар, тәрбиячеләр 40 сәгатьлек «Һөнәри ата-аналар мәктәбе» программасы төзегәннәр һәм алмаш гаилә башлыкларын белемнәрен күтәрергә чакырганнар иде. Чакыруга 30га якын ата-ана кушылды. Иң сөендергәне – алар Казаннан гына түгел, Татарстаныбызның төрле районнарыннан һәм шәһәрләреннән. Күбесе теләсә нинди белгечне өйрәтерлек зур тәҗрибәгә ия. Әмма бала тәрбияләү кебек иң мөһим эштә белем беркайчан да артык булмый. Аннары бер максатлы, бер уйлы кешеләр җыелган җирдә моңарчы төн йокыларын качырган сорауларга да җаваплар җиңел генә табыла.

Укуларда катнашкан әлеге гаиләләрнең һәрберсе турында китап язарлык. Алексеевскида яшәүче 14 ятимне бәхетле иткән Левакиннар үз гаиләләренә балалар алуын белгәч, карачысыз калган сабыйларны алар яшәгән йорт ишек төбенә куеп китү очраклары да булган. Бу гаиләдә төрле милләттән сәламәтлекләре төрле булган балалар бертугандай яшәп яталар. Бу тәвәккәл гаилә хәтта аяклары йөрмәүче кечкенә кызның язмышын да яхшы якка үзгәртә алган. Яшел Үзән районы Норлат авылында балалар йортында эшләүче Рәисә ханым Миңнуллина һәм Наил Латыйпов гаиләсендә дә дистәдән артык ятимгә җылы почмак кына түгел, кочак та табылган. Үзләренеке дә икәү. Ире үлеп тол калгач та, үзе тәрбиягә алган балаларыннан ваз кичмәгән батыр ханым Халидә дә, өч инвалид баланы тәрбияләүче Юля да (ул да сабыйлар йортында эшләгәндә хәлләре авыр нәниләрне гаиләсенә алып тәрбияли) белемнәрен арттырды. Һәр бала үзе бер материк булуын истә тотсак, ә үсмер чорда ул материкларда еш кына җир тетрәүләр, вулкан атулар да күзәтелә, аларның яралы күңелләрен дәваларлык гамәлләрне ничек кылырга, үзен тапмаган бала белән уртак телне ничек табарга, җаннарына ничек ачкыч яратырга? Бу сорауларга җаваплар шул бергә утырып, проблеманы уртага салып сөйләшкәндә табыла. Ярдәмгә психологлар, юристлар да килде. Олы йөрәкле, киң күңелле, шәфкатьле 27 ата-анага әлеге курсларны тәмамлау турында сертификатлар да тапшырылды.

– Курсларны тәмамлаганнар арасында дистәгә якын гаилә үзләренә үсмер балаларны, сәламәтлекләрендә тайпылыш булган һәм куптуганлы ятимнәрне алырга теләкләре барлыгын белдерде. Нәкъ менә аларны гаиләләргә урнаштыру – бүгенге көндә иң зур проблема, – дип, тиздән гаиләле булачак сабыйлар өчен сөенечен яшермәде «Без бергә!» иҗтимагый оешмасының алыштыргысыз рәисе, беренче алмаш гаилә әнисе Татьяна Степанова.

– Һөнәри әти-әниләр мәктәбе бу эшнең мөһимлеген күрсәтте. Шуңа да әлеге башлангычыбыз киләчәктә дә дәвам итәр һәм тагын да зуррак колач алыр дип ышанабыз. Бу хакта ишетеп, башка гаиләләрдән дә гаризалар килә башлады инде, – диде үзәкнең директоры Светлана Богова.

Хәтерләсәгез, бер совет фильмында мондый эпизод бар иде: шактый еллардан соң сыйныфташлар очрашуы бара. Кайсы директор булган, кайсы – мөдир. Һәркайсы үзенең ирешкән уңышлары белән мактана. Ә бер ханым, сыйныфның иң чибәр кызы, оялып кына: «Мин әни булып эшлим», – ди. Ә бу курсларны тәмамлаучылар бу хакта болай оялып түгел, горурланып әйтсәләр дә хаклы.

«Һөнәри ата-аналар мәктәбе»н үткәрү Татарстанның Икътисад министрлыгы гранты ярдәмендә тормышка ашырылды. Шулай бергәләп тотынсак, максатыбыз бер булса, бәхетле җәмгыятькә алай ук ерак та калмас әле, шәт.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

Татарстан Диния нәзарәте тарафыннан 2017 ел – Галимҗан Баруди елы дип игълан ителде. Әлеге тәкъдим белән Диния нәзарәтендә үткән пленумда мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин чыкты, һәм ул бертавыштан хупланды, дип хәбәр итә dumrt.ru.

Татарстан мөфтияте 2017 елны Галимҗан Баруди елы дип игълан итте

– Быел татар дин әһеле мөфти Галимҗан Барудиның тууына февраль аенда 160 ел тула. Галимҗан Баруди кебек танылган дин әһелләрен белергә, аларның китапларын укырга бу юбилей үзе бер сәбәп. Шуның өчен дә бу елны Галимҗан Баруди елы дип үткәрергә тәкъдим итәм һәм рухи мирасыбызны өйрәнергә чакырам, – диде мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин пленум җыелышында.

Мөфти хәзрәтләре агымдагы елда дини өлкәдә башкарылачак кайбер вакыйгаларга да, аерым алганда Болгар ислам академиясен ачуга кагылышлысына тукталды.

– Анда эшләргә яңа коллектив туплана. Кемнәргәдер Болгарга күченергә дә туры киләчәк. Яңа дөньякүләм дини мәгариф үзәген оештыру өчен, Казан белән Болгар арасын шактый таптыйсы була. Бу тарихи идеяне тормышка ашыру җиңел түгел, әмма Болгарга барырга ерак дип утыра алмыйбыз. Хәтта укучы булып та без академияне эшләтеп җибәрергә өлеш кертә алабыз, – диде мөфти хәзрәтләре.

Сүз уңаеннан: Галимҗан Баруди – күренекле дин галиме, мәшһүр җәмәгать эшлеклесе, педагог. 1882 елда ул мәдрәсә ача, ул анда җәдитчә укыта, әтисе хөрмәтенә мәдрәсәгә «Мөхәммәдия» исеме бирә. 1906 елда Казанда аның мөхәррирлегендә «Әд-дин вәл-әдәб» («Дин вә әхлак») журналы чыга башлый. Баруди Россия мөселманнарының сәяси тормышында да актив катнаша. «Иттифак әл-мөслимин» мөселман фиркасе Үзәк комитетының әгъзасы итеп сайлана. Россия мөселманнарының Үзәк диния нәзарәте мөфтие вазифаларын да башкара.

«Милләт йорты»н юксынып

2016 ел минем өчен Казанда «Милләт йорты» кафесы ачылуы белән дә истә калды. Аны Башкортстан татары Рәүф Хәсәнов Нариман урамындагы хәрабә бинаны яңартып сафка бастырды.

1908 елда төзелгән әлеге бина узган гасыр башында басмаханә булган. Биредә әле дә Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал атлап йөргән аяк эзләре җуелмаган кебек. Бинаны булачак исламият галиме мөфти Галимҗан Барудиның туганы үз акчасына салдырган. Гарәп шрифты белән китаплар бастырган бу басмаханәне дөньяның күп почмакларында белгәннәр. Соңрак «Милләт йорты»ның исеме онытылган.

XXI гасырда ул «Милләт йорты» кафесы булып кабат кайтты. Хуҗасы Рәүф әфәнде узган Корбан бәйрәмендә йөзләп кешене хәйрия ашына шушында чакырып кунак итте. Ул кафены арендага биреп, «Милләт йорты»н эшләтеп җибәрергә теләгән иде. Арендалаучының рекламасы булмадымы, кафега йөрүче кеше аз иде. Бераздан кафеның урам яктагы ишегенә йозак эленде.

Кафе булудан тыш, бинаның подвал өлешендә өч-дүрт бүлмәле кунакханә эшли. Монда 300 тәңкәгә кунып чыгарга була. Кафе тирәсендә бер дигән машина кую урыны бар, ләкин ул да Яңа елга кадәр буш торды.

Рәүф әфәнде «Милләт йорты»н алдагы көндә ничек яшәтә алыр? Белеп булмый. Югыйсә нияте зурдан иде. Үз акчасына «Милләт йорты»н торгызгач, калганын милләт үзе кайгыртыр дигәндер ул бәлки.

Җиргә каты басып йөрүче татар байлары Камал театрына бармый тормый югыйсә. Менә шулар тамак ялгарга «Милләт йорты»на йөрсә дә, кафе ишегенә йозак салынмас иде кебек. Казан үзәгендә «Милләт йорты» кафесы гөрләп эшләп торса, ничек күңелле булыр иде дә бит...

Рәис ИДРИСОВ,
Казан.

Самарада «Сәләт»нең беренче кышкы сменасы узды

selet.biz

Самарадагы «Алтын балык» ял һәм сәламәтләндерү лагеренда «Сәләт»нең кышкы сменасы үтте. Ул «Сәләт-Самара» клубының актив эшчәнлеге, «Яктылык» мәктәбе директоры Радик Газизов, ярдәмчесе Фәридә Хәмидуллова һәм сменаның директоры – мәктәпнең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Инзилә Гыйззәтуллина ярдәме белән тормышка ашырылды.

– Смена бер сулышта, бик яхшы узды! Бик көчле әйдаманнар! Соклануымның чиге юк! Балаларны кире өйләренә озатканда, абый-апаларыннан аерыла алмый елап беттеләр. Бу бик күпләрнең иң шәп Яңа ел каникуллары булгандыр, – дип хис-кичерешләре белән уртаклашты Инзилә Гыйззәтуллина.

Җиде көн дәвамында әйдаманнар, чыннан да, балалар белән бик дуслаштылар. Өч төркем сәлкешләр камилләшү дөньясына аяк басты.

Әйдаманнар татар, инглиз, кытай телләре буенча дәресләр уздырдылар. Математика, физика, информатика фәннәрен укытучылар, төрле кызыклы остаханәләр, тренинглар үткәрделәр. «Интуиция», «Түбәтәй», «Top Gear», «Самара кичләре» кебек уеннар һәр баланың күңеленә хуш килде. Сменада кичергән хисләрне янәдән искә алу өчен, катнашучылар «Сәләт-Самара» клубы сафларына кушылырлар дип ышанып калабыз.

Самара шәһәре татар милләтенең танылган вәкилләре үз тормышлары хакында сөйләде, уңыш формуласы белән уртаклашты, тиешле нәтиҗәгә ирешү серләрен чиште.

Мәктәп директоры Радик Газизов һәм Самара шәһәре төбәк Думасы депутаты Минәхмәт Хәлиуллов смена кысаларында Сәламәтлек көне үткәрде. Сәлкешләр атларда йөреп, чаңгы-чанада шудылар, саф һавада уйнадылар.

Сабир ГАЛИМУЛЛИН, «Сәләт-Самара» клубы рәисе:

– Минемчә, беренче смена бик шәп үтте. Җиде көн эчендә узган дәресләр мәгълүматларга бай булды. Һәр бала биредә үзе өчен нинди дә булса файда тапты дип шикләнми әйтә алабыз. «Сәләт»тә моңарчы булмаганнар андагы мохитне чын-чынлап тойды. «Сәләт-Самара» аланы киләчәктә тагын да үсәр дип ышанабыз. Оештыручыларга һәм катнашучыларга бик зур рәхмәт! Алардан башка «Сәләт-Самара» аланы мондый «кызу» булмас иде.

Гөлнара ГАЛИМОВА, сәлкеш:

– Бу минем «Сәләт»тәге алтынчы сменам. Ул кызык, бик тиз, матур узды! Җәйгә кире кайткандай булдым. Каникулларның нәкъ шулай үтүеннән бик канәгать калдым. Әйдаманнар шәп! Балалар бик актив. Беренче көннән үк смена үзенә алып кереп китте. Сәрәннәр, биюләр өйрәндек. Дәресләр, остаханәләр бик файдалы узды. Әйдаманнарга рәхмәтлемен: «Сәләт» мохите тудырдылар. Хәзер балалар тизрәк җәй җитүен көтә. «Сәләт-Самара»ның киләчәге өметле дип уйлыйм.

Адилә РӘХИМОВА, «Сәләт-Самара» клубы активисты:

– Берләшмәдә мин 2014 елдан бирле, сменаны бик көтеп алдык. Әйбәт үтәчәгенә шигебез булмады. Шулай узды да. «Алтын балык»та узган көннәребезне кайта-кайта сагынып сөйләячәкбез әле.

Җиде көн бер мизгел кебек үтте дә китте. Күптән мондый хисләрне кичергәнем юк иде! Сменаның һәр көне үзенчәлекле, кабатланмас булып узды. Бер сәлкеш тә әйдаманының игътибарыннан, җылы мөгамәләсеннән читтә калмады. Алар бөтен вакытларын безгә багышладылар, тормышыбыз белән кызыксындылар, үзләре хакында да сөйләделәр.

Дәресләр дә мәктәптәгегә караганда кызыклырак узды. Фән дөньясына мәхәббәт уяттылар алар бездә. Безнең хәзер үз җырыбыз бар. Инзилә апа бию куйды. Хәзер мәктәбебез коридорларында гел бер җыр яңгыраячак!

Соңгы кич онытылмаслык булды, хәтта күз яшьләре бәреп чыкты.

Смена тәмамлануын аңлау бик ямансу иде. Зур ышаныч белән, «Сәләт-Самара» мин булган иң шәп смена дип әйтә алам!

Чирек гасыр милләткә хезмәттә

Узган гасыр азагында шикләнеп, курка-курка гына ачылган, әти-әниләр тарафыннан да икеләнеп кенә кабул ителгән татар гимназияләре менә инде чирек гасыр буе вакыт сынавын уңышлы узып алга бара.

Автор фотосы

Казан шәһәре Киров районында урнашкан 4нче гимназия дә барлык эш-гамәлләре белән әти-әниләрнең һәм балаларның ышанычын акларга тырыша. Күптән түгел генә гимназия үзенең 25 еллыгын билгеләп үтте. Бәйрәмгә гимназиянең якын дусларының берсе – Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис та килгән иде. Биредә хәтта бер сыйныф бүлмәсендә аңа багышланган музей да бар. Аны татар теле һәм әдәбияты укытучысы Халидә Фәрдиева оештырган. Гимназия укучылары ул яктан бик бәхетле, алар милләтебезгә хезмәт итүчеләр турында дәреслек битләреннән укып кына түгел, якыннан аралашып үсәләр. Биредә озак еллар эшләп килгән Сара Садыйкова музеена аның кызы Әлфия Айдарская да еш килеп йөри, әнисе турындагы истәлекләр белән уртаклаша. Ренат ага Харисны да монда көтеп торалар. Гимназия көненә ул беркайчан да буш кул белән килми, иң сәләтле, иң иҗади, иң тырыш өч укучыга ел саен үзенең шәхси премиясен тапшыра. Әлеге бүләкнең беренче лауреатлары арасында бүген Кәрим Тинчурин исемендәге театрның яшь сәхнә йолдызы, сәләтле артисткасы Резидә Сәләхова да бар. Үзенә ныклы белем биргән, талантын ачкан гимназиягә, укытучыларга, Ренат Хариска тагын бер тапкыр рәхмәт әйтергә дип, бәйрәмгә ул да килгән иде. Дистә елдан артык вакыт гомер эчендә әлеге мәртәбәле бүләккә гимназиянең 30 укучысы һәм биш иҗади коллективы лаек булган. Быел исә бу бүләккә 9нчы сыйныф укучысы Камилә Хәкимова һәм 7нче сыйныфтан Регина Шакирова («Бәллүр каләм» номинациясе), 6нчы сыйныфтан Фәридә Ваһапова («Яшь рәссам» номинациясе) җиңеп, халык шагыйренең үз кулыннан бүләк алдылар. Ренат Харис музейга Россия Президенты Владимир Путиннан килгән котлау хатын, үзенең чынаягын һәм Мәскәү Кремленнән махсус алып кайткан яшел карандашны бүләк итте. Бәйрәмгә яшь композитор, милли опералар авторы Эльмир Низамов та килгән иде.

– Мондый бәйрәм-юбилейлар безне үткәннәргә карап шөкер, киләчәккә карап фикер йөртергә өйрәтә, халык арасында милли уку йортының абруен күтәрә, укучыларыбызның горурлыгын арттыра. Хәзерге катлаулы заманда бу иң мөһиме, – диде гимназия директоры Илхания Вахитова.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

«Незамерзайка»ның сукыр калдыруы ихтимал

Иркутск шәһәрендә йөзгә якын кешенең метанолдан ясалган «Боярышник» эчеп һәлак булуы хакимият органнарын да, халыкны да сискәндереп җибәрде. Спирт катнашмалы продукция җитештерүчеләргә һәм сатучыларга ил күләмендә плannan тыш тикшерүләр үткәрелә хәзер.

Дамир БӘДРИЕВ

Республикадагы хәлләр белән Роспотребнадзор федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Марина Трофимова таныштырды. Казан, Чаллы, Түбән Кама, Алабуга, Бөгелмә, Саба, Зәй, Азнакай, Мамадыш, Актаныш, Апас, Яшел Үзән, Алексеевск, Югары Ослан, Балтач, Болгар, Лениногорск, Нурлат, Лаеш, Чистай, гомумән, республиканың барлык төбәкләрендә сатыла торган парфюмерия-косметика һәм көнкүреш химиясе продукциясендә метил спиртының (метанол) тиешле нормалардан артык булуы ачыкланган.

– Апаста эшкуар Фәйзуллинаның «Автозапчасти» кибетендә сатыла торган автомобиль тәрәзәсен юа торган «Super Tech» сыеклыгында метанол катнашмасы – нормадан хәтта 902 мәртәбәгә артык, – дип мисал китерде Марина Трофимова. – Ә метанол чын мәгънәсендә агу, ул кешенең нерв һәм йөрәк системасына зыян сала, күзләр сукыраерга мөмкин.

Мәскәү шәһәреннән, Владимир, Ульяновск, Түбән Новгород һәм Мәскәү өлкәләреннән стандартларга җавап бирмәүче «незамерзайка»лар республикага сатуга кайтартылган. Автомобиль тәрәзәсе юдыргычлары «Капелька», «LAZUR», «SKYLU», «NORD STREAM»га метанол күп кушылган.

– Россиядә автомобильгә хезмәт күрсәтүдә файдаланыла торган сыеклыклар җитештергәндә метанол кулланылмый. Хәзер изопропил спирты файдаланыла. Изопропил спиртыннан ацетонга охшаш ис килә, ләкин сәламәтлеккә зыяны юк. Автоһәвәскәрләр иссез һәм арзан бәяләрдәге сыеклыкларга алданмасыннар. Техник таләпләргә җавап бирүче «незамерзайка»ның бәясе 200 сумнан да ким була алмый, – диде Казан милли-тикшеренү технология университетының (КНИТУ-КХТИ) нефть һәм нефть-химиясе факультеты деканы профессор Наталья Башкирцева. – Метанол кушылган очракта да, ул йөзгә биш өлештән артмаска тиеш.

Метил спиртын эчәргә һич тә ярамый! 50 миллиграмм метил спиртын куллану нерв системасын боза, сукыраюга китерә, ә 100 миллиграмм эчкәндә, үлем яный.

Марина Трофимова искәрткәнчә, лосьонда һәм гигиена максатларындагы башка төрле сыеклыкларда этил спирты да продукциянең 25 процентыннан артырга тиеш түгел.

Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсенең «кайнар элемтә» телефоны: атнаның эш көннәрендә **(843) 236-94-11** һәм ял көннәрендә **(843) 238-98-54. 10.00-17.00** сәгатьләрдә хәбәрләшергә мөмкин.

19 гыйнварда христианнар Хач ману бәйрәмен билгеләп үтә. Бәйрәм алды кичендә һәм бәйрәм көнне чиркәүләрдә гыйбадәт кылу һәм суны изгеләндерү йоласы башкарыла. Аруландырылган су көчле дәвалау үзлегенә ия дип санала. Әлеге су, имеш, ел дәвамында бозылмый, саф кала.

Хач ману бәйрәме җитә

Суга чуму өчен, кагыйдә буларак, хач формасындагы махсус бәкеләр – иорданьнар ясала. Казанда шундый биш урын әзерләнәчәк: Авиатөзелеш районында урнашкан Щербаково бистәсендәге Зәңгәр күлдә, Идел буе районында Югары Кабанда (Борисково, 54 тирәсендә), Киров районының Спас Нерукотворный храмында; Казансу елгасында; Никольский чиркәве каршында. Чиркәүләрдә бәйрәм гыйбадәтләре иртәнге сәгать 8.00дә башланачак. Иорданьнарны изгеләштерү – сәгать 11.00-12.00 тирәсендә. Хач ману йоласы вакытында полиция һәм ашыгыч ярдәм хезмәте эшләячәк.

Инҗил буенча, Иордан елгасында булган Чукындыручы Иоанн янына 30 яшьлек Гайсә Коткаручы килә һәм, бер гөнаһы булмаса да, үзен өч мәртәбә суга чумдырып, арулавын сорый. Иоанн гаҗәпләнсә дә, Гайсәнең теләген үти. Арулану йоласын үтәгәннән соң, Гайсә Коткаручы, Изге Рухка ияреп, үзенең пәйгамбәрлек миссиясенә догалар уку һәм ач торып әзерләнү өчен, 40 көнгә чүлгә китә. Православие динендәге дингарның өч мәртәбә суга чумуы — аның тәне һәм җанының гөнаһлар өчен үлүен, ә судан чыгуы — Гайсә Коткаручы терелгән кебек, яңадан терелүен аңлата.



Өстәгеләрне коткарып булмаячак

Казанның гражданнарны яклау идарәсенең эзләү-коткару отряды хезмәткәрләре узган ел 258 кешене үлемнән коткарган.

– Коткарылганнарның 42се – балалар, – дип басым ясап әйтте шәһәр башкарма комитетының гражданнарны яклау идарәсе җитәкчесе Фердинант Тимурханов «эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә.

Казанда узган ел 724 янгын теркәлгән, 143 кеше коткарылган. Кызганыч, 23 кеше ут эчендә калып һәлак булган. Башкаладагы барлык мәктәпләр янгын хәбәрен җиткерә торган автомат җайланмалар белән җиһазландырылган. Ун җәйге ял лагерена, 37 балалар бакчасына ПАК «Стрелец-Мониторинг» аппарат системасы көйләнелгән.

Узган ел 3,1 миллион сумга 220 янгын гидранты төзекләндерелгән.

– Хәзер 4294 гидрант төзек, бу – шәһәрдәге барлык гидрантларның 98 проценты, – диде Фердинант Тимурханов. – Шәһәр янындагы яшел зоналарда 222 километр озынлыкта махсус ерымнар ясалды. Табигатькә чыккан очракларда да ут белән сак эш йөртү сорала.

Узган елның җәйге айларында 13 кеше суга батып үлгән. Казан эчендәге сулыкларда кешеләрнең батып үлүенә юл куелмаган. Әлеге нисбәттән, шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе Денис Калинкин, докладчыга кушылып:

– Сулыкларның төбе тикшерелгән, оештырылган урыннарда гына коенырга кирәк. Рөхсәт булмаган урыннарда коенырга ярамый, – дип үз фикерләрен өстәп куйды.

Җитәкченең бу сүзләрен быелга алдан кисәтү, дип кабул итәргә буладыр. Төрле хәбәрләр һәм киңәшләр Kzn.ru сайтында Гражданнарны яклау идарәсе битенә дә урнаштырылган.

112 – коткару хезмәте телефоны. Кешеләрдән алынган ярдәмгә чакыру хәбәрен ашыгыч хезмәтләргә тапшыру 2015 елда ун минутка кадәр сузылган булса, хәзер ул 3-4 минутта ук хәл ителә. Бердәм дежур-диспетчерлык хезмәте хезмәткәрләре махсус өйрәнү-күнегүләр узган. Әмма хәбәр секундлар эчендә алынганда да ярдәм килеп җитмәскә яки коткару эшләре нык кыенлашырга мөмкин.

– Казанда тугыз каттан да биегрәк булган йортларга хезмәт күрсәтә алучы махсуслаштырылган техника юк әлегә. Башкортстан үзендә андый машинаны булдырды инде, – дип борчылып әйтте Фердинант Тимурханов.

Йомгаклау сүзендә шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе Денис Калинкин Казанда узган ел 32нче мәктәптә чыккан янгында укытучылар коллективының һәм янгын сүндерүчеләрнең төгәл чаралар күргәнлекләрен, шул рәвешле балаларга зыян салынмавын искә төшереп узды һәм өйрәнү-күнегүләрнең мөһимлеген искәртте.

Рәдиф КАРАГАЙ.

Буалылар «Идел-Урал» фестиваленә әзерләнә

Буа татар дәүләт драма театры 13-15 гыйнварда казанлыларга Туфан Миңнуллинның «Кияүләр», Зөлфәт Хәкимнең «Килә ява, килә ява», Сөләйман Латыйповның «Кодалар-кодачалар» спектакльләрен тәкъдим итте.

Люция ХӘБИБУЛЛИНА

tatar-inform.ru

«Гөргөри кияүләре»н алар үзенчәлекле итеп, нәкъ үзләренчә куйган. Тамашачы аны яратып карады. Заманында әсәрнең авторы Туфан Миңнуллин әлеге спектакльне карагач та ошатып җиткермәгән. Ә аннары аның камаллыларча куелмавы белән килешкән. Репертуарларындагы «Килә ява, килә ява» спектаклен Фәрит Бикчәнтәев сәхнәләштергән. Коллективта профессиональ булмаган артистларның да үз рольләрен кызыклы итеп башкарулары тамашачыны сөендерә.

– Соңгы берничә елда Буа театрының үсеше күренә. Моннан 10-12 ел элек без аны «Мунча ташы» белән чагыштыра идек. Хәзерге вакытта алар җитди әсәрләргә алына башладылар. Фәрит Бикчәнтәевнең Буага барып спектакль куюы да шуны раслый. Быел 12-22 мартта Буада «Идел-Урал» театрлар фестивале уздырырга ниятлиләр. Анда монголлар да, казахлар да киләчәк. Фестиваль үткәрергә кыюлык кирәк, – ди театр тәнкыйтьчесе Нияз Игъламов.

Буада театр 1917 елда артист Бари Тарханов тарафыннан оештырыла. Алар беренче мәртәбә «Казанга сәяхәт» дигән спектакль уйныйлар. Быел коллектив әнә шул 100 еллык юбилейларын да зурлап билгеләп үтәргә җыена. Сәнгать җитәкчесе Раил Садриев тырышлыгы белән яңадан оешкан театр 2000 елда дәүләт театры исемен алды.

– Без юбилейга әзерлекне ике ел элек башладык инде. Узган ел 19 театрны чакырып, фестиваль үткәргән идек. Балалар фестивале дә уздырабыз. Декабрь аенда «Пирамида» күңел ачу үзәгендә театрның 100 еллыгы билгеләп үтеләчәк, – диде ул.

– Фестивальгә чит җирләрдән килгән кешеләргә үзебезнең төбәкнең матурлыгын да күрсәтәсе килә. Шуның өчен авылыбызны төзекләндерүгә көч куябыз, – ди театрның башкарма директоры Фәрит Садриев.

Автор фотосы

Татарстан хөкүмәте карары нигезендә, узган ел Казанда һәм республиканың башка шәһәрләрендә сентябрь аеннан башлап, авыл хуҗалыгы ярминкәләре үткәрелгән иде. Халык анда сәүдә челтәрләрендәге бәяләрдән 20-30 процентка арзанракка азык-төлек сатып алды.

Казанда көн саен ярминкә

Узган елның 24 декабрендә оештырылган ярминкәдә казанлылар авыл хезмәтчәннәрен һәм агропредприятиеләрне моңсуланып озатып калды.

Шөкер, аерылышу озакка бармады. Казанда янә ярминкәләр дәвам итә. Шимбәне көтәсе түгел, ярминкә көн саен!

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының азык-төлек базарын үстерү бүлегендә аңлатуларынча, фермерлар махсуслаштырылган сәүдә чатырларында көн саен сәүдә итә. Арадашчылар кертелми, фермерлардан урын өчен түләү алынмый, продукция сәүдә челтәрләрендәгедән 20 процентка кадәр арзанрак.

Казандагы махсуслаштырылган сәүдә чатырлары адреслары: Юлиус Фучик урамы, 64; Липатов урамы, 7; Зәкиев урамы,12; Дементьев урамы,7; Беломорская урамы белән Гудованцев урамы кисешкән чат; Батыршин урамы, 20 һәм Лаврентьев урамындагы 10нчы йорт янәшәсендә. Фермерлар 7.00-12.00 сәгатьләрдә сәүдә итә.

Дамир БӘДРИЕВ.

«Фиксики»ны татарча карыйбыз

Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы хәбәр иткәнчә, 60 серияле популяр Россия мультфильмын хәзер татар телендә дә карап булачак.

youtube.com

Мультфильм Татарстанда телләрне саклау буенча дәүләт программасы кысаларында тәрҗемә ителгән.

Исегезгә төшерәбез, моңа кадәр «Малыш и Карлсон», «Винни-Пух», «Крокодил Гена» һәм башка мультфильмнар тәрҗемә ителгән иде.

Интернетта – «Вәли» мультипликация сериалы

«Вәли» мультипликация сериалының сынау рәвешендә ясалган бер сериясе Интернетта социаль челтәрләрдә тәкъдим ителде.

Алга таба аны 10-15 серияле итеп әзерләү ниятләнелә. Бу хакта «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы хәбәрчесенә «Тасма» медиа студиясе җитәкчесе Әнвәр Оразов хәбәр иткән.

Әңгәмәдәш үзе идея авторы булып тора.

– Без татар теле үсешенә үз өлешебезне кертергә теләдек. Бер ел элек шушы мультфильмны төшерүне максат итеп куйдык, аны үз акчабызга эшләттек. Без үзебез продюсер һәм режиссер да, – ди ул.

Тавышны яңгыратуда студия вәкилләре үзләре дә катнашкан, таныш артистларын, «Татар радиосы» хезмәткәрләрен дә җәлеп иткән.

Әнвәр Оразов, Татарстанда андый дәрәҗәдәге осталарны тапмаганлыктан, Мәскәү аниматорларына мөрәҗәгать иткәнлеген билгеләп узды.

– Искәртеп утәм, ул – сынау рәвешендә төшерелгән серия. Бу режиссер варианты гына, ягъни инвесторлар, каналлар өчен. Белгечләргә күрсәтеп, кайсы җирен үзгәртү, алмаштыру, эшләп бетерү буенча тәкъдимнәр алу өчен. Без бер сезонга булса да акча җәлеп итү бурычын куйдык. Бу – мультсериал, бер сезонга аның 10-15 сериясе булыр дип фаразланыла. Без шушы сезон өчен ярдәм эзлибез. Хәзер эш бизнес-план булдыру стадиясендә, – дип белдергән студия җитәкчесе.

Шәһри КАЗАН

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)

www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.
ЧЫГАРЫЛЫШ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ – РАСИХА ГАБДЕЛБӘР кызы ИСМӘГЫЙЛОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+

Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1551. Гомуми тираж – 6187.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 664. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор) 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77– 50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы.
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы